# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**№ 1**

**13 ноябрь 2020 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 09.00 сәгатьтә, үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 200 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Чукмарлы авылында авыл мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Чукмарлы авылы зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту(ягулык-майлау материаллары,трактор өчен запас частьләр сатып алу,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Чукмарлы авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Чукмарлы авылы спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (ком ташу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 241 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 157 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 157 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл жирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 200 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Чукмарлы авылында авыл мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Чукмарлы авылы зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту(ягулык-майлау материаллары,трактор өчен запас частьләр сатып алу,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Чукмарлы авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Чукмарлы авылы спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (ком ташу) кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Хадиуллин